**Республика Татарстан**
**Иляксазское сельское**
**поселение Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль**
**районының Илексаз**
**авыл җирлеге**

---

**РЕШЕНИЕ**

25 январь 2016 ел

**КАРАР**

**№ 5**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Илексаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турында нигезләмәне раслау

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 56 статьясы һәм Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Илексаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәне расларга 1 нче кушымта нигезендә.

2.Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге башлыгына әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту йөкләнде.

Илексаз авыл җирлеге
Советы рәисе

Ф.М.Гильфанов